ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кукмара муниципаль районы
Нырты авыл җирлеге Советы

КАРАР

2020 елның 28 гыйнвары 3 номерлы

Нырты авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Нырты авыл җирлеге карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге Нырты авыл җирлеге Советының 29 номерлы карарына (Нырты авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 28 номерлы, 2015 елның 15 маендагы 22 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 12 номерлы, 2017 елның 17 июнендәг 08 номерлы, 2018 елның 12 ноябрендәге 26 номерлы, 2018 елның 12 ноябрендәге 29 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 29 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 22 номерлы,2019 24 декаберендэге 26 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кадастр хакының 0,1% ы – 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук Нырты авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында да.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Нырты авыл җирлеге
башлыгы: Т.АКутдусов

ОГРН 1021607754563
ИНН 1623001710